ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

18.12.2019

Казан шәһәре

**КАРАР**

№ 4-3/г

Татарстан Республикасы халкына көнкүреш ихтыяҗлары өчен сатыла торган сыегайтылган газга 2020 елга ваклап сату бәяләрен билгеләү хакында

«Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы 69-ФЗ номерлы федераль закон, Монополиягә каршы федераль хезмәтнең «Халыкка көнкүреш ихтыяҗлары өчен сатыла торган сыегайтылган газга ваклап сату бәяләрен җайга салу буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2019 елның 7 августындагы 1072/19 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы халкына көнкүреш ихтыяҗлар өчен сыегайтылган газга түбәндәге күләмнәрдә календарь буенча бүленгән ваклап сату бәяләре билгеләргә (НДС исәпкә алып):

1.1. 2020 елның 1 гыйнварыннан 2020 елның 30 июненә кадәр:

- газны кулланучыларга кадәр җиткерүдә транспорт чыгымнары бәясен исәпкә алмыйча, 1 килограммы өчен 29,49 сум;

1.2. 2020 елның 1 июленнән 31 декабренә кадәр:

- газны кулланучыларга кадәр җиткерүдә транспорт чыгымнары бәясен исәпкә алмыйча, 1 килограммы өчен 30,37 сум.

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С. Грунчев